УДК 398.341

***З.М. Брусько***

# ҮЗ КУЫШЫҢ – ҖАН ТЫНЫЧЫҢ
## (татар халкының өй салу белән бәйле ышанулар һәм гореф-гадәтләр комплексы)

Статья посвящена исследованию традиционного обряда строительства дома у татар, раскрывающего культурные особенности и символику этого значимого события в жизни семьи и общины. Автор подробно описывает последовательность действий, начиная от выбора места и подготовки материалов до завершения постройки и заселения. Особое внимание уделяется поверьям и обычаям, связанным с началом строительства, сборкой сруба, закладкой фундамента, установкой матицы, кладкой печи, угощением работников, а также обряду переселения йорт иясе / өй хуҗасы (духа-хозяина дома), направленного на защиту нового дома от невзгод и привлечения благополучия. Анализируются магические практики, связанные с выбором места для строительства, а также символика таких ключевых элементов, как матица и печь, выполняющих сакральные функции. Отдельно рассматривается обычай коллективной помощи (өмә) и ритуал нигез боткасы (каши основания), обеспечивающий плодородие и достаток новому жилищу. В статье на богатом полевом материале показано, как строительные обряды татар отражают мифологические представления, социальные нормы взаимопомощи и семейные ценности, способствуя трансляции культурного опыта и поддержанию социальных связей в татарской сельской среде.

**Ключевые слова:** татары, дом, строительство, сруб, помочи, обычай, поверье

The article focuses on the traditional ritual of building a house among the Tatars, revealing the cultural features and symbolism of this significant event in the life of a family and a community. The author provides a detailed description of the steps involved, from choosing the location and preparing the materials to completing the construction and moving in. Special attention is paid to the beliefs and customs associated with the beginning of construction, the assembly of the log cabin, the laying of the foundation, the installation of the tie beam, the laying of the stove, treats for workers, as well as the Yort iyase / Oy khujasy (Brownie) rite of relocation, which aims to protect the new home from adversity and attract prosperity. The article examines the role of house-building rituals in transmitting cultural ideas, preserving tradition, and maintaining social ties in the Tatar rural community.

**Keywords:** Tatars, house, construction, log cabin, help, custom, belief

Татар традицион мәдәниятендә өй салу кеше һәм гаилә тормышының әһәмиятле этапларыннан берсе буларак кабул ителә. Өйле булу, үз өеңдә яшәүнең кыйммәте халык мәкальләрендә дә чагылыш таба: «Үз куышың – җан тынычың», «Үз йортың – туган анаң» «Тавык оясы хәтле булса да, үз өең булсын», «Яман булса да, өең булсын», «Карт булса да, ир булсын, кыек булса да, өй булсын» [9: 351–353]. Өйсез кешегә булган мөнәсәбәт тә мәкальләрдә ачык күренә. «Өе

юк кеше кеше типкесендә үләр», «Өйсез – эш көйсез», «Өйсез кеше туңар», «Өйсез ир – ирсез хатын», «Өйле көләр, өйсез бөләр», «Өй салсаң үсәрсең, салмасаң үчәрсең (кирегә китәрсең, бетәрсең мәгънәсендә)» [шунда ук] кебек мисаллар йорт-җирсез кешенең социаль һәм көнкүреш хәлен бәяләүне күрсәтә.

Өй салу, аның өчен нигез урынын сайлау, ул урынның тыныч, чиста булуын тәэмин итүче ышануларга нигезләнгән йолаларны үтәү зур эшләрдән санала. Нигез урынын җентекләп сайлыйлар. Иң элек аның элеккеге юл яки ызан өстенә туры килмәвен кайгырталар. Әлеге гамәл халык күзаллауларында әлеге урыннарның куркыныч, зәхмәтле җир буларак кабул ителүе белән бәйле. Бу күзаллаулар, үз чиратында, ызанны ике (кешелек һәм параллель дөнья) арадагы чик дип уйлауга кайтып кала. Юкка гына әби-бабаларыбыз элек-электән ызанга утырырга, ятарга, бигрәк тә ятып йокларга ярамый, дип искәртеп тормаганнар. Бу тыюны бозган очракта кешегә зәхмәт кагыла, ул чиргә сабыша, дигәннәр. Шул ук вакытта халыкта «ызаннан изгеләр, фәрештәләр йөри, шуңа күрә анда нигез корырга ярамый, нигез тынгысыз, борчулы була» дигән ышану да яшәп килә. Өйне кайчандыр мунча яисә каралты-кура торган урыннарга да салмаска тырышалар. Болай эшләгәндә, мунча иясе, абзар иясе ачуланырга, йорт хуҗаларына һәртөрле бәла-каза, мал афәте җибәрергә мөмкин, дип санала.

Булачак нигез урынын төрле чүп-чардан чистарткач, ат яки трактор белән сукалап чыгалар. Бу гамәлләрнең нигезендә күңелдә булган төрле шикләнүләрдән арыну, нигезне сихер, бозым ише «кара көчләр»нең үтеп керүеннән саклау теләге ята. «Нигез урының чирәмле булса, аны кырып алырга, себереп түгәргә кирәк. Шулай эшләсәң, нигезең тыныч, хәвеф-хәтәрсез була, гомерең дә бәхетле, озын була», дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә йорт салучы кешеләрдән [Авторның кыр материаллары. Информант: М.С. Әсгарова (1928), ТР, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы. 2006]. Әлеге ышануның чагылышын халкыбызның төш юрауларында да очратабыз. Төштә кемнең дә булса нигезенә үлән үскәнен күрүне анда яшәүчеләрнең нәселе бетүгә, коруга юрыйлар. Нәкъ менә шуңа күрә дә нигезнең нык, нәселнең дәвамлы булуын теләп, халык нигез урынын әзерләүгә бик җитди карый.

Өй салу бура бураудан башлана. Гадәттә, һәр авылда бу эшнең бөтен нечкәлекләрен дә белүче осталар була. Авылдагы бер генә йорт, мунча, келәт, сарай бурасы да алар катнашыннан башка салынмый, күрше-тирә авылларга да гел аларны чакыралар, чөнки эшнең рәтен беләләр, тиз һәм җиренә җиткереп эшлиләр. Көздән урманнан кисеп алып кайткан агачны кыш көне кузгатмыйлар. Эшкә, яз җитеп, карлар шактый эрегән көннәрдә – апрельнең башы-урталарында тотыналар. Бу вакытта агач шактый йомшарган, эченә төшкән туң эрегән була. Борынгы заманнардан ук урман янында гомер сөргән бабаларыбыз бура бурау өчен агачның кайсы төре яраклы икәнен яхшы белгәннәр. Иң яхшысы – чыршы, ак чыршы я нарат, аларны юнәтеп булмаганда, усак, юкә әзерләнгән. Бураны шушы агачларның бер генә

төреннән бурарга тырышканнар, чөнки бер агачның икенчесе белән килешмәвен, бергә туры килгәндә, бик тиз арада чери башлаячагын да аңлаганнар. Бу бигрәк тә усак белән юкәгә, берсе дымлы, икенчесе йомшак агачларга кагылган. Ә менә каен агачыннан бураны бөтенләй бурамаска тырышканнар. Халыкта «Каен – кайгы агачы», дигән әйтем бар. Бу аның элек-электән зиратта каберләр өстенә утыртыла торган агач булуы белән бәйле. Халык телендә зиратны «каенсар» дип атау әле дә очрый. Моның нигезендә «үлгән затларның җаны шул каен агачларында яки шунда сайрап йөргән кошларда саклана» дигән бик борынгы караш ята [14: 66]. Шуңа күрә дә татар кешесе бу агачны төзелештә куллану түгел, өй тирәсенә утыртырга да тырышмый.

Авыл тормышында өй җиткереп керү һәрвакыт зур һәм мәшәкатьле эш булып торган, күп кешенең моңа еш кына берничә ел гомере сарыф ителгән. Шуңа да карамастан, гаиләләр үз йортларын салып чыгарга, өйләнгән улларын да йорт-җирле итәргә омтылган. Йортларны ныклы һәм озакка җитәрлек итеп салу мөһим саналган. Бу караш халык мәкалендә дә чагылыш таба: «Ярап торырга хатын алма, ярап торырга өй салма, өең башыңа ишелеп төшәр» [9: 354] дигән әйтем йорт салуга җаваплы мөнәсәбәтне белдерә.

Бура бурау, бураның зурлыгына карап, ун-унбиш көн дәвам итә. Бу эштә ашыгу-кабаланунның кирәге юк, балта осталары үз эшләрен ипләп кенә башкара. Ә башкарасы эш аз түгел – бүрәнәләрне каезлыйсы, таслыйсы, тиешле озынлыкта кисеп чыгасы, почмакларын чабасы, паҗ аласы бар. Халыкта йөрүче «Өй салуның ние бар: мүклисе дә чутлыйсы!», «Өй салу нәрсә – сипләргә дә мүкләргә», «Өй салуның ние бар: өйдең – өй, كактың – чөй» [9: 352] дигән әйтемнәр бу эшнең читтән карап торганда гына ансат күренүен, ләкин чынлыкта күп хезмәт, осталык һәм тәҗрибә таләп итүен күрсәтәләр.

Бура бураганда агачны әрәм итмәскә тырышалар: бүрәнә чапканда чыккан йомычкаларны кич белән яки эш туктап торган арада җыеп, утын лапасына ташыганнар, соңыннан аларны мичкә ягу өчен файдаланганнар. Паҗланган, ян-яклары чабылган бүрәнәләр бура итеп җыела; бу этапта алар ниргә дип атала. Өйне, гадәттә, ун-унике, кемдер хәтта ундүрт ниргәле итеп сала. Биек итеп салынган йорт авыл җирендә аерым күренеп торган.

Бура күтәрелеп беткәч, инде башка төр эшләргә дә керешергә вакыт җитә. Осталар ниргәләргә, буталмасын өчен, тышкы яктан саннар сугып чыгалар да өйнең эчке якта каласы якларын чутлый башлыйлар, чутлаган бер ниргәне җиргә алып куеп баралар. Ишек, тәрәзә буласы урыннарны билгеләргә дә онытмаска кирәк, идән, түшәм такталарын, матчаны алдан әзерләп кую да – хуҗаларга зур ярдәм. Булачак өйнең нигезен дә күпвакыт бура бураучылар корып куя. Бу – аларга йөкләнгән эшләрнең иң соңгысы, әмма иң җаваплысыдыр, мөгаен. Нигез кору – зур осталык һәм төгәллек таләп итүче эш. Күпвакыт салыначак өйнең ныклыгы нәкъ менә нигезнең дөрес итеп корылуыннан тора. Бу турыда безгә халкыбыз мәкальләр аша да

җиткергән: «Бураның аскы бүрәнәсенә иң авырлык», «Өйне сала башлаганчы, нигезен ныгытырга кирәк», «Нигезне кыек салсаң, түбәсен тимерказык йолдызына хәтле меңгерсәң дә кыек булыр» [9: 351].

Нигез урыны билгеләнгәннән соң, йортны күтәрү мәшәкатьләренә керешәләр. Йорт күтәрү – күмәк көчсез башкарып чыгара торган эш түгел, шуңа күрә хуҗалар авыл халкын өмәгә дәшә. Өмә традицион авыл җәмгыятендә үзара ярдәмләшү формасы булып тора. Иртәгә өй күтәрәбез дигән көнне бөтен туган-тумачага, күршеләргә, авылдашларга, балта осталарына өмә буласын әйтеп чыгалар. Чакырылган кешеләр, гадәттә, ярдәмгә килергә ризалык белдерәләр. «Өмәгә дәшсәләр, ничек тә килергә тырышалар, хәтта эштән сорап ук калалар иде. Көн дә өмә булмый бит. Кеше сүзен тыңламасаң, үзеңне дә санламаулары бар», – дип искә алалар кайчандыр йорт күтәргән авыл кешеләре. Шулай итә торгач, өмәчеләр саны ун-унбиш кешегә җыела [Авторның кыр материаллары. Информант: М.С. Сабиров (1931), ТР, Теләче районы, Олы Нырсы авылы. 2006]. Эш, гадәттә, иртә таңнан башлана. Өмәдә катнашучылар арасында тәҗрибәле осталар да, йорт күтәрү эшенә беренче тапкыр килгән яшьләр дә була. Информантлар өмә көненең аяз булуын да еш искә ала; бу күзәтү йорт күтәрүнең хәерле башлануы белән бәйләп аңлатыла.

Татар халкының йорт күтәрү өмәсе – бай эчтәлекле, төрле магик йолалардан торган үзенчәлекле күренеш. Йорт хуҗаларының киләчәктә яңа нигездә игелекле, бәхетле, бай, мул тормышта яшәячәкләренә ышануга бәйләп, аларны һәр яңа салынучы йортта башкарырга тырышалар. Нәкъ менә шул теләк белән, күтәреләчәк йорт нигезенең дүрт почмагына мулладан яздырып алынган догалар, көмеш тәңкәләр куеп калдырыла. Аларны, гадәттә, «Нигез урынында тузсын, тигезлектә, муллыкта, ашлы-сулы булып яшәргә насыйп булсын», дигән сүзләр белән хуҗа кеше куя.

Бер рәт ниргә куелып беткәч, борынгыдан килгән гадәт буенча, өмәчеләрне «нигез боткасы» («диңгез боткасы») белән сыйлыйлар. Бу да – яңа нигезгә муллык, бәрәкәт, тынычлык иңдерү теләге белән башкарылучы гамәлләрдән. Хуҗабикә пешереп алып чыккан кап-кайнар ботканы, гадәттә, эштә катнашкан барлык кешеләр дә өйгә кермичә, ниргәгә утырган килеш кенә ашыйлар. Ботканың нинди булуы мөһим түгел, ул карабодай, дөге я тары ярмасыннан булырга мөмкин. Ләкин шул ук вакытта ботканың пешерелүе үзе зур мәгънәгә ия гамәл булып тора. Татарларның игенчелек традициясе белән бәйле көнкүрешендә ботка төп һәм туклыклы ризыкларның берсе саналган. «Ботка ашаганның буыны нык» [9: 464] дигән мәкаль дә шуны раслый. Ботка тиз һәм җиңел әзерләнә, шуңа күрә көндәлек тормышта да, төрле йолаларда да гаять киң кулланылган. Йорт күтәрү өмәсенә пешерелүе исә боткага дигән ярманың бөртекле, димәк, күләмле булуына бәйле. «Ярманың бөртеге күп, шуңа күрә савабы да күп була. Аны пешергән вакытта, хәерле ризыклар булсын, нигезебездә ризыгыбыз күп, мул булсын, дигән теләкләр тели-тели пешерәбез», – ди өмәчеләргә

ботка пешереп ашатучы хуҗабикәләр [Авторның кыр материаллары. Информант: М.С. Әсгарова (1928), ТР, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы. 2006]. Нигез боткасы белән бәйле гадәтләрнең тагын берсе – аны урамнан узган һәр кешегә, күршеләргә авыз иттерү [4: 282]. Бу гадәт күршеләр белән ризык бүлешү, яңа нигез шатлыгын уртаклашу һәм савап алу теләге белән аңлатыла. Халык телендә киң таралган «Күрше хакы – Тәңре хакы», «Күршелек кардәшлектән якын», «Күршесез йорт-кура торгызалмассың», «Күршегә онга кермәсәң дә, көлгә керерсең» [10: 11–13] кебек мәкальләр күрше белән күрше мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. Күршелек мөнәсәбәтләренең әһәмияте авыл җәмгыятенең эчке бәйләнешләре, үзара ярдәмләшү һәм уртак хуҗалык-көнкүреш тәҗрибәсе белән бәйле.

Күршеләр үзләре дә өмәдән читтә калмыйлар, ир-атлар йорт күтәрешергә ярдәм итсә, хатын-кызлар бүрәнә арасына кыстыру өчен салам үрү эшен башкара. Бу эш иртән иртүк көянтә-чиләк белән су ташудан башланып китә. Саламны чылату өчен су күп кирәк. Кичтән үк озын тактага йөз иллеле кадак кагып, «тарак» ясап куялар. Монысы – мунчала тарау өчен. Бу эшне исә күп вакыт инде кул арасына керерлек булган бала-чагага тапшыралар.

Төш вакытында өмәчеләр өчен уртак табын әзерләнә. Информантлар өмә көнендә табынга харам ризык кертелмәвен, йорт хуҗаларына изге теләкләр теләнүен ассызыклый. Ул көнне бөтен туган-тумача, күрше-күлән ризык алып килә. Кем – аш, кем – йомырка, кем – ботка, май, сөт, ипи. Хатын-кызлар җиргә зур җәймә җәеп, алып килгән ризыклардан табын кора. Бу күренеш «ызба ашы», «нигез ашы» дип атала. Олылардан соң табынга өмә эшендә катнашкан балаларны да чакыру гадәте булган. Кичке ашны әзерләүдә дә туганнар һәм күршеләр катнаша. Алар: «Нигез ашы китердем, Аллаһы Тәгалә саулык-сәламәтлек, тигезлек белән шушы нигездә яшәргә язсын сезгә», – дигән сүзләр белән өмәчеләрне шулпа, бәлеш һәм башка ризыклар белән сыйлыйлар. Кайчандыр аерым мәгънәгә ия булган нигез ашы китерү гадәтен аңлату бүген беркадәр үзгәреш кичергән, хәзер ул савап алу, саваплы булу теләгенә кайтып калган. «Нигез ашы китерүнең савабы икеләтә зур, беркемнең дә савапсыз каласы килми, хәленнән килгәнчә ярдәм итәсе килә», дигән сүзләрдән моны ачык күрергә мөмкин [Авторның кыр материаллары. Информант: Ә.Х. Әсгаров (1926), ТР, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы. 2006].

Өмә комплексында тагын бер ышану аерым игътибарга лаек. Ул өмәчеләрнең кунак табынына аш китергән кешеләргә күчтәнәч бирмәү белән бәйле. Кунак табыныннан күчтәнәч биреп җибәрү гадәте киң таралган булса да, йорт күтәрү өмәсендә моның киресе күзәтелә; әлеге үзенчәлек халык ышанулары белән аңлатыла: нигез ашы китергәннәргә күчтәнәч бирмәү нигезнең бөтенлеген, анда яшәячәк гаиләнең иминлеген сакларга ярдәм итә. Авыл халкы «Нигез ташын, нигез ашын таратма. Нигез ашы өеңнән чыкмаска, нигездә калырга, нигез ризыклы булырга тиеш», дигән сүзләрне буыннан буынга тапшырып,

бу тыюны сакларга тырыша [Авторның кыр материаллары. Информант: Л.Х. Мингарипова (1965), ТР, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы. 2006].

Төшке ялдан соң өмәчеләр матча урнаштыру эшенә керешә. Матча йортның иң мөһим конструктив өлешләренең берсе булып санала, чөнки ул түшәмне һәм түбә корылышын тотып тора. Шуңа күрә аны, гадәттә, нык дип исәпләнгән нарат яки чыршы агачыннан ясарга һәм бу эшне тәҗрибәле остага тапшырырга тырышканнар.

Матча урнаштыру эше зур осталык белән беррәттән үз авылының гореф-гадәтен, элек-электән килгән тәртипләрне белүне таләп итә. Гадәтләрнең бер ише матчаны күтәргәндә аңа эченә яңа пешкән ипи, атланмай төреп салынган толып (сөлге) бәйләп менгерүдән, урнаштырган кешеләрнең шушы ризыкны ашауларыннан [3: 123; 11: 100], ә кайдадыр осталарга ипи бәйләнгән сөлгене бүләк итүдән гыйбарәт [15]. Шул ук вакытта, матча күтәрү уен-көлке элементлары, өмәчеләр белән хуҗалар арасында барган алыш-биреш формасында да оештырылырга мөмкин. Еш кына матчаны астан күтәрүчеләр күтәрә алмаганга салыналар, я инде күтәргәч, тиешле урынына урнаштырган вакытта матчаның «кыска булуы», «туры килмәве» турында хәбәр итәләр, шул рәвешле хуҗалардан «матча мае», ягъни сый сорыйлар [5: 125; 2: 271]. «Матча мае» атамасына килгәндә, кайдадыр бары тик шушы сыйны гына белдерүче әлеге атама, башка җирлектә тар мәгънәдә кулланылу белән беррәттән, гомумән матча күтәрү күренешенә карата да кулланыла башлаган. Әлеге гадәт матчаның йорт корылышында һәм халык күзаллауларында мөһим урын тотуын күрсәтә.

Матча – йортның конструктив элементы, практик әһәмияткә ия предмет кына түгел, ә биредә яшәүчеләрнең тормышында мөһим саналган вакыйгалар барышында һәрдаим исәпкә алынып, йолаларында кулланылып, аларның борынгыдан килгән күзаллауларын чагылдыра торган, сакраль мәгънәгә ия җайланма да. Горизонталь яссылыкта караганда, бураның нәкъ уртасыннан үтүче матча өйне урамнан керү өлешенә һәм түр якка, ә вертикаль яссылыкта – эчке һәм тышкы (үз һәм чит) өлешләргә бүлеп тора. Әлеге бүленешләргә бәйле үзенчәлекле гореф-гадәтләр барлыкка килгән. Әйтик, урамнан килеп кергән кешенең хуҗа рөхсәтеннән башка матчаны узмаска тиешлеге, яучының, сүзе үтеп, буш кайтмавын тәэмин итү өчен, нәкъ менә матча турына утырырга тырышуы, йокы урынын, шул исәптән бала бишеген дә матчадан читтәрәк урнаштыру, армиягә китүче егетнең тешләнгән ипи кисәген матчага кыстырып куюы һ. б. Өмәчеләр матчаны урнаштырганда, яхшы теләкләр тели-тели, аның астына көмеш тәңкә, догалык, ә кайбер якларда йон кисәге салып калдыралар. Бу да матчаның халык күзаллауларындагы урынын билгели.

Матчага бәйле күзаллаулар мәкальләрдә, табышмакларда һәм юрауларда да чагылыш тапкан. Кинаяле сүз белән әйтелгән «Атасы аркылы яткан, балалары буй яткан», «Бер мендәрдә алтмыш солдат йоклый», «Бердән-берәү, алтмыш егеткә терәү», «Алтмыш атка бер

ияр» [13: 136] кебек табышмаклар, «Ата – йортның матчасы, ана – йортның өрлеге, балалар – стенасы» [9: 239] мәкале, төш юраулар (төштә матча сынганын күрү – гаилә башлыгының үлеменә) матчаның йорт һәм гаилә бөтенлеге белән бәйләп аңлатылуын күрсәтә.

Матчаны урнаштырып бетергәннән соң, булачак өйгә тәрәзәләр һәм ишекләр уела. Эш барышында аларның урыннары алдан билгеләнә. Гадәттә, урам якта ике, йорт алты почмаклы булып буйга салынган очракта, дүрт яки биш, ян-якта тагын берничә тәрәзә уела. Өйнең ишек-тәрәзәле булуы практик яктан гына түгел, халык ышанулары яссылыгында да әһәмиятле. Бу ышанулар арасында төштә бура күрү теге яисә бу кешенең үлемен хәбәр итүе турындагысы да бар. Борынгы төрки-татар традициясендә кабер өстенә бура урнаштыру гадәте булу [1: 151–152] аның үлгән кешенең «өе» вазифасын үтәве турында сөйли. Шуңа бәйле рәвештә халыкта салына торган өйнең ишексез-тәрәзәсез калмавына зур игътибар бирелгән, «тәрәзәсе уелмаган өйгә чыгарга ярамый», «тәрәзәсез мунчада юынырга ярамый» дигән тыюлар сакланып килгән. Бу тыюлар нәселне хәвеф-хәтәрдән, көтелмәгән үлемнән саклау теләге белән аңлатыла.

Йорт күтәрү эшләре түбә ябу белән тәмамланса да, хуҗалар анда күчеп яши башлаганчы, тагын күп эш башкарыла: тәрәзә, ишекләрне эшләтеп алып, урыннарына урнаштырырга, идән-сайгаклар җәяргә, мич чыгарырга кирәк. Мич – йорт, нигезнең төп атрибутларының берсе, ул ризык, муллык, бәрәкәт, иминлек төшенчәләре белән бәйләнгән. Бу үзенчәлек учакка, утка бәйле борынгы күзаллаулар белән аңлатыла. Утка хөрмәт күрсәтү, аны изгеләштерү мотивлары мич белән бәйле ышануларда һәм йолаларда да дәвам итә. Бу ышанулар арасында миче чыгарылган яңа өйне ялгыз калдырырга ярамау, анда шул ук көнне кемнең дә булса кунарга тиешлеге турындагысы да бар. Әлеге ышануның мәгънәсен ачыклау йөзеннән халкыбызның мифологик күзаллауларына мөрәҗәгать итеп, яшәү урыны мич тирәсендә дип исәпләнгән йорт иясен (өй хуҗасын) ялгыз калдырмау белән бәйле булуын аңларга мөмкин [6: 848]. Халыкның «Өйнең яме мич белән», «Мичсез өй – мисез баш», «Мичкә ут керде – өйгә кот керде», «Ут якмаган өй кура белән бер» [9: 358–359] мәкальләре өйнең мичле булуы белән бергә аның ияле, димәк имин, хәвеф-хәтәрсез булуы турында да сөйли. Бу күзаллауны халык телендә йөрүче «мич чыгаргач та, өйне ялгыз кундырсаң, өй тынгысызлана, өйгә җеннәр ияләшә» дигән сүзләр дә куәтләп тора.

Мич халык күзаллавында еш кына җанлы, кешегә хас сыйфатларга ия итеп, бигрәк тә көннең күп вакытын мич янында аш-су әзерләп уздырган хатын-кыз кыяфәтендә гәүдәләндерелә. Күпсанлы табышмакларыбыз моңа мисал булып тора: «Асылбикә асыл кия, күлмәге җиргә тия», «Түше кара әбием түргә карап утыра», «Өй почмагында озын хатын утыра», «Ак тутамның авызы зур булса да, аш ашый алмый» һ. б. [13: 140].

Мич һәрвакыт өйнең тәрәзә уелмаган өлешенә, авызы белән я түр якка я арт якка каратып, артыннан үтеп йөрер өчен бераз ара (ара-

лык) калдырып чыгарыла. Монда, гадәттә, хуҗабикә аш-су әзерләгәндә көндәлек кулланышта булган кисәү агачы, пумаласы, ипи көрәге, табагач, савыт-саба өчен киштәләр урнаштырыла. Еш кына аралык, түр якка үтмичә генә, өйнең аш-су бүлмәсе итеп файдаланыла торган өлешенә керү юлын да үти.

Мич чыгару җаваплы һәм катлаулы эш саналган, шуңа күрә аны махсус оста башкарган. Һәр авылда булмаса да, берничә авылга хезмәт күрсәтүче оста миччеләр булган. Яхшы мичче чыгарган мичнең җылысы идәннән түшәмгә кадәр бертөрле, һавасы суларга рәхәт, тәрәзә рамнарында, пыяласында дым барлыкка килми, дип бәяли информантлар. Шуңа күрә хуҗалар миччегә эш барышында тиешле хөрмәт күрсәтергә һәм аны ризалатырга тырышкан. Халык телендә, тиешле мөнәсәбәт булмаган очракта, кайбер миччеләрнең хуҗаларга зыян китерүе турында да сүзләр йөри: моның өчен алар мичнең төтен чыгу юлына кош мамыгы кыстырып, я пыяла кисәге куеп калдыралар, нәтиҗәдә, төтен морҗага китмичә, кире өйгә чыга, Мондый хикәятләр мичче һөнәренә һәм аның осталыгына бирелгән символик әһәмиятне күрсәтә.

Мичнең чыгарылып бетерелүе – хуҗалар өчен әһәмиятле вакыйга. Остадан эшне кабул итеп алгач, утынлыктан бер кочак утын алып кереп, яңа мичкә тәүге тапкыр ут кабызыла. Элек бу гамәл «яңа ут алу» йоласы белән бәйләнештә башкарылган: ут агачны агачка ышкып кабызылган. Аларның ышанулары буенча, мондый ысул белән кабызган ут төрле авыру, эпидемияләрдән саклаган [12: 520]. Яңа өйнең яңа мичен якканда да, әлеге йоланы үтәүнең нигезендә шушы ышану ята.

Яңа йортка күченү йолаларының мөһим өлеше – йорт иясен (өй хуҗасын) күчерү. Төрле якта төрле ысуллар кулланып башкарылган бу йоланың асылы һәр очракта да бер генә – өй иясенең йортның бәрәкәтен, иминлеген, тәртибен, анда яшәүчеләрнең исәнлеген сакларга ярдәм итүенә ышану. Шуңа күрә дә әлеге йоланы һәр төбәктә кабул ителгән кагыйдәләр буенча башкарырга тырышканнар. Әгәр дә бер авылда ата-бабадан калган гадәт буенча йорт иясен себерке, пумала, табагач, ипи көрәгенә, я булмаса, ат арбасына «утыртып» алып киләләр икән, икенче авылда аның хуҗалар күченгәндә үзе аларга ияреп килүенә ышаналар, моның өчен аңа үзеңнән калмаска өндәп мөрәҗәгать итү җитә дип санала. Халык традициясендә йорт иясенең ниндидер сәбәпләр белән яңа йортка күчмәве турында да хәбәр ителә. Бу исә кешенең яңа нигездә мантымавына, биредәге тормышы рәтсез булуга китерә, дип ышаналар [7: 51–55]. Йорт иясенең яңа нигездә «урнашуын» хуҗалар аннан ишетелгән төрле тавышлар (он иләү, җеп эрләү, чабата үрү), үзләрен кайгырту (сәхәргә уяту, сыер бозаулаганда уяту) гамәлләре аша беләләр. Йорт иясе хуҗаларына хәерхаһлы булсын өчен, ышанулар буенча, аны «сыйлау», аңа мөрәҗәгать итү, садака бирү кирәк саналган. Яңа өйдә йорт иясе үзенең беренче ризыгын – хуҗалар аңа дип пешереп алып килгән һәм мич башына, мич алдына, ә кайдадыр өй базының дүрт почмагына куелган ботканы нәкъ менә

күченгән көнне «кабул итә». Кайбер хуҗалар исә яңа өйгә күченгән көнне пешерелгән «нигез боткасы»н үзләре белән бергә ашасын өчен, йорт иясенә дип, өстәлгә аерым тәлинкә-кашык куялар, аны шул рәвешле бәхилләтергә тырышалар. Йорт иясенең күңелен күрү аңа өйдә ныклап урнашырга ярдәм итү, аны кирәксезгә борчымау, тынычлыгын бозмау кебек гамәлләрдән тора. Бу гамәлләр йорт иясен саклаучы көч буларак кабул итүгә нигезләнгән ышанулар белән бәйле. Мәсәлән, татар кешесе яңа өйне анда бер ел яшәмичә юмый, чөнки бу гамәле белән яңа нигезгә әле генә күчеп килгән, ныклап урнашып өлгермәгән йорт иясен борчудан шикләнә. Хуҗабикә яңа өйнең эчке киңлеген тәртипкә китерә, аны «киендерә»: тәрәзә араларына – өлеңге, матча, мич һәм стена буйларына – кашага, бүлмә араларына чаршау элә. Йорт иясенең изгелегенә ышануны «өй җимерелеп, йорт иясе матча астында калса да, аңа зыян килми икән», дигән сүзләр белән аңлаталар [Авторның кыр материаллары. Информант: Г.Ә. Пулатова (1941 елгы), ТР, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы. 2006].

Яңа өйгә керү дә аерым йола тәртибендә башкарыла. Ата-бабадан калган гадәт буенча хуҗалар бусаганы, «бисмилләһ» әйтеп, уң аяктан атлап керәләр. Кулларында ашъяулыкка төргән бөтен икмәк була, ә теләкләре йортның иминлеге һәм бәрәкәте белән бәйле: «Я Раббым, шушы өебездә сәламәтлек белән бәрәкәтле, мул тормышта яшәргә насыйп ит, хәвеф-хәтәрләрдән, күз тиюләрдән, дошманнардан, сихерчеләрдән, җен-пәриләрдән үзең сакла» [Авторның кыр материаллары. Информант: Р.Х. Гарифуллина (1935 елгы), ТР, Биектау районы, Олы Битаман авылы. 2006]. Бу теләк яңа йорттагы тормышның имин һәм хәерле булуына өмет-ышанычны белдерә. Кайбер төбәкләрдә өйгә иң элек песи кертү гадәте дә теркәлгән. Электән башкарылып килгән һәм бүгенгәчә сакланган бу гадәтне алар песинең төкле хайван булуы, төкле хайванның исә бәхет китерүе белән аңлаталар. Бу ышану халыкта песигә бәйле тагын бер ышануга барып тоташа: «Йортка килеп кергән песине чыгарып җибәрергә ярамый, болай эшләсәң, ул үзе белән синең бәхетеңне дә алып чыгып китә», дип аңлатыла. Әлеге ышанулар төкнең (йонның) халык күзаллауларында муллык, бәрәкәт, бәхет символы буларак чыгыш ясавына нигезләнә. Халык күзаллауларында йонлы куллы, йонлы аяклы кешене бәхетле кеше дип исәпләү, кияү йортына аяк басучы киленне «төкле аягың белән кил» (ягъни, бәхетле аягың белән кил) дигән сүзләр белән каршылау, аны йонлы ягы тышка әйләндерелгән тунга бастыру гамәлләре – шушы күзаллауларның чагылышы.

Шулай итеп, татар халкының өй салу белән бәйле йолалары һәм ышанулары йорт җиткерүнең бары тик көнкүреш ихтыяҗын гына канәгатьләндерә торган гамәл булмавын күрсәтә. Нигез сайлау, нигез кору, матча күтәрү, өмә үткәрү, мич чыгару, йорт иясен күчерү, нигез ашы үткәрү кебек йолалар татар халкының йортны иминлек, муллык, нәселне дәвам итү һәм рухи тормыш белән бәйле сакраль объект итеп кабул итүен чагылдыра. Әлеге йолаларда мифологик күзаллаулар, ярдәмләшүгә нигезләнгән иҗтимагый мөнәсәбәтләр, гаилә

кыйммәтләре һәм көнкүреш тәҗрибәсе үзара үрелеп бара. Шуңа күрә йорт салу белән бәйле гореф-гадәтләр татар халкының традицион мәдәниятен генә түгел, ә аның дөньяга карашын, яшәү рәвешен һәм мәдәни хәтерен өйрәнүдә дә әһәмиятле чыганак булып тора.

**Әдәбият**


1. *Әхмәтҗанов М.* Татар зиратлары // Казан утлары. 1997. № 12. Б. 143–153.

2. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

3. *Баязитова Ф.С.* Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 197 б.

4. *Баязитова Ф.С.* Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: Матбугат йорты, 2007. 480 б.

5. *Булатова М.Р.* Татар теле көнбатыш диалектының стәрлетамак сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз. Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. Беренче кисәк. Казан: ТӘҺСИ, 2019. Б. 87–130.

6. *Davletshina L.Kh., Mavlyautdinov I.S.* Semiotic Status of the Folklore Image of the Stove in Traditional Culture of the Tatars // RES MILITARIS. 2022. Vol. 12, no. 3. P. 846–852.

7. *Давлетшина Л.Х.* Дом как форма освоения «чужого» пространства // Известия Уральского федерального университета. Серия 2: Гуманитарные науки. 2012. № 1 (99). С. 49–56.

8. *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 623 б.

9. *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 749 б.

10. *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 799 б.

11. *Рамазанова Д.Б.* Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре: хрестоматия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 565 б.

12. *Рәхим Г.* Сайланма әсәрләр / Төз.: М.И. Ибрагимов, А.М. Гайнетдинов. Казан: Ихлас, 2018. 560 б.

13. Татар халык иҗаты. Табышмаклар / Томны төзүче, искәрмәләрне хәзерләүче һәм кереш мәкалә язучы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 271 б.

14. *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: I т. (А-Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

15. Эх, күңелле өмәсе! URL: https://syuyumbike.ru/news/goref-gadet/ekh-kelle-mse (мөрәҗәгать итү көне: 20.05.2026).



***Брусько Зәлия Мансур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Брусько Залия Мансуровна,***
*кандидат филологических наук, научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*zalesh@list.ru*